ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 13 марты № 13

Татарстан Республикасы “Түбән Чыршылы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196нчы "Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында” 2018 елның 24 гыйнварындагы 32нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5 946,47 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Түбән Чыршылы авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат

стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый-мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина

1нче кушымта
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Түбән Чыршылы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 13нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында “Түбән Чыршылы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе, *сумнарда*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Гробны, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 2 252 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 1 126 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 2 568,47 |
| **Барлыгы** | **5 946,47** |

2нче кушымта
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Түбән Чыршылы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 13нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында “Түбән Чыршылы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең бәясе** | **Хезмәтләрнең бәясе, *сумнарда*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне каплау | 560 |
| 3. Гробны, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 1 692 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 1 126 |

| | |
|---|---|
| 5. Погребение (рытье могил и захоронение) | 2 568,47 |
| **Барлыгы** | **5 946,47** |